ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

23.08.2019　　　　　г.Мензелинск　　　　　№ 818

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 07.12.2018 елдагы “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының архив эше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына раслау турында”гы №1370 карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы №2010-ФЗ Федераль законы нигезендә, ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. 1.3.1. пунктының 2 абзацында түбәндәге административ регламентларга үзгәрешләр кертергә:

-1 нче кушымта нигезендә архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

-2 нче кушымта нигезендә кулланучыга муниципаль архивның уку залында эшләү өчен архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- 3 нче кушымта нигезендә юридик затларга архив эшендә һәм эшләр белән идарә итүдә документларны оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

-4 нче кушымта нигезендә архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

-5 нче кушымта нигезендә ябылучы оешмаларның шәхси составы буенча документларны муниципаль архивка саклауга кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

1.1.« 423700, ТР, Минзәлә шәһәре, Ленин ур., 80 нче йорт» адресын «423700, ТР, Минзәлә шәһәре, Коммунистик урамы, 32 нче йорт» адресына алыштырырга.

1.2. «8(5555)3-16-30» телефон номерын «8(5555)3-50-72» телефон номерына алыштырырга.

3.Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarsnan.ru) рәсми порталында бастырырга һәм интернет мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче К.Р.Нәҗмиев